С(Баш)К)
Н 93

Нажар
НӘҖМИ

ТАТАР КАНЫ



Башкортстанның Дүртөйле районы Миңешт авылында туганмын.

Бөтен шигырьләремне мин башкорт телендә язам, әмма ләкин татар темасы — татар халкының фаҗигале тарихы, аның язмышы — гомерем буе минем йөрәгемне тетрәтте һәм шуларга һичвакытта битараф кала алмадым; киләчәктә дә алар мине бик нык уйландырачак.

Бу китапка кергән шигырьләрне әнә шул уйфикерләремнең җимеше дип кабул итсәгез иде.

Нәҗар НӘҖМИ

Нажар
НӘҖМИ

ТАТАР
КАНЫ

ШИГЫРЬЛӘР

МӘГЪРИФӘТ
УФА • 1997

Башкортстан татар телле
язучылар союзы
тәкъдиме нигезендә нәшер ителә

145 561

Национальная библиотека
имени Ахмет-Заки Валиди
08

Нажар Нәҗми. Татар каны. Шигырьләр һәм поэма. — Уфа, «Мәгърифәт». 1997 ел. 85 бит.

ISBN 5-9000166-07-X © Мәгърифәт 1997 ел.

Милли җаным

Әниемнең карынынан,
Әтиемнең барлыгыннан
Бар булган ул йөрәк каным.
Шул канымның йөрешендә,
Йөрәгемнең тибешендә
Милли җаным, милли җаным.

Ата-бабам гомер сөргән,
Кеше булсын дип үстергән —
Җирдә ыру-тамырларым,
Шул җиремнең сулышыннан,
Рухымнан, булмышымнан
Килә минем милли җаным.

Ул җир үзенчә серләшә,
Туфанчалап та сөйләшә
Су буенда үскән талым.
Кыркып алсаң бит талларың
Сарыккан батыр каннары —
Башкорт каны — милли җаным.

Гомер буе кешелекле,
Кешеләргә изгелекле
Җирем-суым, аткан таңым,
Башкаларга охшамаган
Башкага холкын такмаган
Мәңге тыйнак милли җаным.

Титул өчен сатылмаган,
Сузылмаган, тартылмаган,
Саклап калган ул дүрт санын,
Гасырлар буе таланган,
Кимсетелгән һәм тапалган,
Җәберләнгән милли җаным.

Үзенчә ул горур, бөек,
Күкрәк сукмас, кәпәч чөеп,
Үз акылы — акыл аның.
Мин имансыз булыр идем,
Чәчкә кебек сулыр идем
Синнән башка, милли җаным.

1989

Татар теле*

Вы, прадеды наши в недоле
мукою запудривших лик,
на мельнице русской смололи
заезжий татарский язык.

Ярослав СМЕЛЯКОВ

Туган җирең Идел буе,
Һәр телнең бар туган иле.
Туган җирең кебек назлы,
Җырдай моңлы татар теле.

Ак алъяпкыч бәйләсәләр,
Өзелеп тора кызлар биле.
Кызлар кебек шат чырайлы,
Ачык йөзле татар теле.

Халкың кебек уңган да син,
Хезмәттә син көне-төне.
Ир-егетләреңдәй дәртле,
Гайрәтле син, татар теле.

Фәннән сине аерса да
Гасырларның афәт җиле,
Аксакалларыңдай олпат,
Акыллы син, татар теле.

Ассалар да, киссәләр дә
Үлмәдең син, калдың тере.
Чукындырган чагында да
Чукынмадың, татар теле.

---

* А. Локманов музыкасы

Яндың да син, туңдың да син,
Нишләтмәде язмыш сине.
Дөньяда күп нәрсә күрдең,
Әй, мөкатдәс Тукай теле.

Төрмәләргә дә яптылар
Җәлил белән бергә сине.
Төрмәләрдә дә килмешәк
Булмадың син, татар теле.

Зинданнарны ярып чыктың,
Ялкынланып чыктың кире,
Хәтта фашист тегермәне
Тарта алмады анда сине,
Әй син, батыр татар теле!

Кабатланмас үткәннәрең —
Гасырларның яман чире.
Кабатлар сине гасырлар,
Татар теле, дуслык теле.

1966

* * *

Мин үземә һәйкәл куя алмадым —
Балкырдаен җырлар нурыннан.
Булдым заман колы, ә колларга
Кайда, нинди һәйкәл куелган?

Куйган аны халык мәхәббәте
Шагыйренә борын-борыннан,
Әгәр үзе мәхрүм ителмәсә
азат җирле халык булудан.

Кеше йөрәгендә мин дә, димен,
Урын алдым, бугай, аламын!
Әмма кеше җирдән китә бара,
Ә мин кайда, кемдә каламын?

Кем атар соң минем исемемне
Туган җирдә, туган телемдә?
Әгәр дә ул өйдәш булып калса
Үз өенда, туган өендә.

Мин үземә һәйкәл куя алмадым —
Балкырдаен җырлар нурыннан.
Туган телсез мин юк! Ә юкларга
Кайда нинди һәйкәл куелган?

1972

Бар!

Гасырлардан, иске заманнардан
Тутыкмаган иске хәбәр бар.
Кем әйткәндер, кайчан әйтелгәндер:
«Татар барда, — диеп, — хәтәр бар».

Кайда гына хәтәр юк икән соң?
Ул бар, булган һәм ул булачак.
Хәтәрсезме булды безнең заман,
Безнең яшьлек, безнең балачак?

Безгә генә килгән кебек иде
Дөньяның бар хәтәр көннәре.
Яуда гына күпме ятып калды
Татарның да кеме, кемнәре?!

Хәтәр барда да бит татар бар ул.
Барган икән унау үлемгә,
Аның берсе — бер билгесез Әхмәт, —
Туры килүме бу? Кем белгән...

Бер кабердә өчәү ята икән,
Аның берсе — татар егете.
Туры килүме бу? Әллә бары
Горурлануыммы үз итеп?..

Кайда бакма — хәтәр җирдә татар,
Адәм ышанмаслык даны бар.
Карбышевтан кем сораган? Ә ул:
«Миндә, — дигән, — татар каны бар».

Кая бакма — хәтәр җирдә татар,
Үлемнәрнең сыртын сындырып,
Утлардан да, Моабитлардан да
Кем соң чыкты моңлы җыр булып?

Палач балтасына башны тотып,
Көлеп үлгән икән татарлар,
Дошман өчен, сатлык җаннар өчен
Татар барда, чынлап, хәтәр бар...

Бар!

1975

Таяк

Татарстан белән Чечня Русия референдумында катнашмадылар.

Хәбәрләрдән.

И хакыйкать! — килде заман,—
Тарих өстеннән төшмә.
Коллыкта бит бертуганнар
Татарва белән Чечня.

Коллык дигән зур таякның
Алар бит ике башы:
Иң тәүге кол татар булса,
Соңгысы чечен халкы.

Дүрт гасыр озынлыгында
Шул коллык дигән таяк.
Ике башның арасында
Күпме мыскыллы хәят!

Күпме кан һәм кимсетелү,
Күпме күз яше, хәсрәт.
Яман шеш булып тулышты
Тарих тәнендә нәфрәт.

Ничәмә гасыр ул таяк
Империягә тотка.
Димәкчеләр: суга батмас,
Ул таяк янмас утта...

Әй акыл!

1993

Алар өчәү иде

Алар өчәү иде: Хәсән Туфан,
Сибгат Хәким, Кайсын Кулиев.
Күз алдымда Туфан карашлары,
Сибгат йөзе, Кайсын көлүе.

Алар өчәү иде... Ә өчесе бер җан —
Җан-агайлар миңа, җан-дуслар.
Өчесе дә кеше йөрәгендә
Нур балкыткан алтын йолдызлар.

Алар өчәү иде... Өчесе дә
Гомеремә булды өч терәк.
Күңелемә — күңел, җырыма — җыр,
Йөрәгемә моңлы бер йөрәк.

Исән чакларында мин аларның
Барып күрдем туган җирләрен.
Вафат булгач, туган җирләренә
Һәрбересен барып җирләдем.

Әмма алар терелләрдән тере —
Үлем юк ул, юк бит җырларга.
Ә мин үлгәч, алар өчесе дә
Килер кебек мине җирләргә.

Үлем юк ул, юк бит җырларга!

1986

Хәтер көне

«Хәтер көне игълан ителде».
Татар гәзитләреннән.

«Кто старое помянет, тому глаз вон»
Урыс халык әйтеме.

Үткәннәрне хәтерләмә, имеш,
Хәтерләми кара үткәнне.
Оныт, имеш, синең өскә ничек
Күпме гасыр пычрак түккәнне.

Күпме гасыр халык йөрәгеннән,
Милли яралардан кан тама.
Татар өчен җәбер, мыскыл нәрсә,
Рус өчен бәйрәм, тантана.

Хәтерләми кара... Хәтерләтеп
Үткәнеңне Кызыл мәйданда,
Аждаһадай, тугыз башлы храм
Сине гел кисәтеп торганда.

Кайтты бүген хәтер көне генә.
Ә хәтердә коллык, күпме кан.
Киләчәгең булмаячак, татар,
Үткәнеңне әгәр онытсаң.

1991

Шагыйрьләр һәм хатыннар

ТаССРның халык артисты
Рәшидә ханым ҖИҺАНШИНАГА.

Кышкы Казан иде. Урамда
Декабрьнең иде салкыны.
Чәчкә сипте шагыйрь юлына
Чәчкә кебек татар хатыны.

Әй шагыйрьнең берчә чалт аяз,
Берчә болыт баскан язмышы!..
Шул язмышның сезгә, хатыннар,
Уртак икән кайсы яртысы?

Ә шагыйрьләр сезнең юлларга
Нинди чәчкә икән сиптеләр?
Аларныңмы сезне сөюе
Калды эзсез... Эзсез үттеләр?

Алардан бит сезгә төште нур...
Ә соңыннан инде гомергә
Сүнмәс йолдыз булып үзегез
Балкыдыгыз җирдә, күңелдә.

Бернс һәм Джин, Пушкин һәм Натали,
Матильдалар* яшәү ямендә,
Мәгъруур җыры булып заманның
Кушылдылар Җәлил-Әминә.

---

* М а т и л ь д а — Генрих Гейне хатыны.

Җырда мәңге калыр өченме,
Анна Керн, башка-бүтәннәр,
Даһилар бит сезне, сылулар,
Безнең өчен дә бит сөйгәннәр.

Тетрәп киттем... Шагыйрь юлына
Чәчкә сипте татар хатыны.
Кышкы Казан иде. Урамда
Декабрьнең иде салкыны.

Булгандыр бит...

Габдулла ТУКАЙГА

Булганнар бит бөек шагыйрьләр —
Тугач, урын — алтын бишектә.
Үскәч — киткән, кайткан чакларда,
Кеше торган саклап ишектә.

Булган тагы бөек шагыйрьләр,
Тар бүлмәдә череп сүнгәннәр.
Бала чакта исә базарда:
«Асрарга бала бирәм! — дип,—
Кем ала?!» — дип сатып йөргәннәр.

Әй, язмышның шомлы агышы,
Бөеклекнең алтын ярлары...
Гомерендә — халкы язмышы,
Җырларында — халкы моңнары.

Хәзер инде башка заманнар,
Заманнарда башка базарлар,
Базарларда — башка малайлар,
Малайлар да — башка Нажарлар.

Күңелемнең заман кошчыгы!—
Басып сайрый алтын киртәгә.
Сатылырга бүген әзермен,
Тукай чыкса миннән иртәгә.

«Йә, кем ала?! Сезгә кирәксәм,
Мин тукталам табып мәрхәлә*.»
Аһ, алай да килми кешегә
Шагыйрь дигән бөек мәртәбә.

1969

* Мәрхәлә — юлчылар туктап китә торган урын.

145561

Национальная библиотека
имени Ахмет-Заки Валиди

Беренчесе

Шәехзадә БАБИЧКА

Дүртөйледән без дүртәүбез*—
Аннан башлап, миндә бетә.
Дүртнең дәвамын якташлар
Аның кебекләрдән көтә.

Күпме еллар инде киткәненә,
Безнең гомер еллар санында.
Алтын орлык арасында тавык
Тибенгәндәй, үлек җанында
Тибенәбез һаман, чокынабыз...
Үлгәч тә бит түгел ул тыныч.
Үлгәннәрдән дәме без куркабыз,
Гомереме әллә куркыныч?..

Мондый язмыш кемгә тәтегән соң —
Балкып сүнүе дә үзенчә.
Күпме кешеләрнең язмышына
Керде хәтта үле көенчә.

Нигә шулай? Әллә аның рухы
Артык усал, артык яманмы?
Әллә заман аны аңламыймы,
Улмы аңламады заманны?
Их, барсы да аңлашылып торса,
Ул да булмас иде үзенчә.
Мин дә язмас идем бу шигырьне,
Аннан өлкән малай көемчә.

---

* Шәехзадә Бабич, Бәдрүш Мокамай, Зыя Мансур һәм шушы юлларның авторы.

Дүртөйледән без дүртәүбез —
Аннан башлап, миндә бетә.
Дүртнең дәвамын якташлар
Аның кебекләрдән көтә.

1969

Кичер мине

Муса ҖӘЛИЛГӘ

Демблин, Радом, Берлин...
Шул юллардан
Алып барды сугыш сине дә.
Шул юллардан дошман,
чигенә-чигенә,
Алып киткән икән мине дә.

Бер үк юлда ике төрле язмыш...
Ә мин шунда исән калганмын.
Әйтерсең лә, дошманнарны куып,
Мин тик сине эзләп барганмын.

Хәтерлимен төрмә коймаларын,
Бәреп кергән тимер капканы.
Үз күзләрем белән күргәнмен мин,
Үз кулларым белән тотканмын мин
Сине харап иткән балтаны.

Бу хәтерләү нигә кирәк хәзер —
Синең даның шуңа калганмы?!
Палачларга сине бирмәс идем,
Кичер мине — соңлап барганмын!

1957

Ак җилкән

(Хәсән Туфан)

Белеет парус одинокий...
М. Лермонтов

Уфаларга килсә, урамнардан үтә,
Йә булмаса бизәп араны,
Утыра ул безнең белән бергә
Ялгыз җилкән кебек агарып.

Ул ялгыз да һәм ялгыз да түгел,
Безнең белән утырып янәшә,
Ул яшьлеге, ул бүгене белән,
Киләчәге белән сөйләшә.

Без дә хәзер бик карадан түгел,
Без дә хәзер инде агарган.
Ә барыбер, бергә утырсак та,
Без малайлар әле, малайлар.

Ак башында кара кайгылармы,
Әллә микән Себер карлары?
Бардыр инде, барысы да бардыр —
Сөзәк түгел гомер ярлары.

Бардыр инде, барысы да бардыр,
Шагыйрь гомере — бару юл ярып,
Бер агаргач, кабат караймыйча,
Ул яшәсен шулай агарып —
Юк, акланып түгел, агарып!

Бардыр инде, барысы да бардыр,
Җиңел түгел гомер юллары.
Бөтенесе бергә төйнәлгән бит —
Язмыш моңы, шигырь моңнары.

Уфтану ят аңа, ишеттермәс
Яшәү хакында ул авыр сүз.
«Бер газапсыз шагыйрь буламыни,
Океан буламыни давылсыз?!»

1969

Чит тел аша...

Рәсүл ГАМЗАТОВКА

Онытмыймын, берчак шулай, белгәч,
Мин Мостайдан өлкән икәнне,
Синең миңа: «Нигә болай булгач,
Син билгеле түгел?» — дигәнне.

Өйрәнелгән синең тапкырлыкка,
Сүзләреңнән озак көлештек.
Көлештек тә, шәрабыңны эчкәч,
Без үбештек бугай, үбештек!

Дустыңның мин дусты булган өчен
Дус күрәсең бугай бүген дә.
Ул турыда синең шигырь дә бар —
Сөйләдең син авар телендә.

Яшермимен, синең кебек данлы
Кеше белән, ничек булса да,
Дус булуы ул горурлык, димен,
Яшәү җиңелрәк доньяда.

Тик авырдыр сезнең кебекләргә,
Бигрәк тә синең кебеккә.
Чит тел аша күпме
«...Шагыйрьләрнең
Баш өстеннән» сикереп биеккә.

Очар өчен кирәктер ул булу
Үз халкыңның Пушкин, Тукае.
Ә соң Тукай, Мәхмүт бөтен илгә
Синдәй билгелеме, дускаем?

Һәр юлында очкын чәчрәп тора,
Ут булмый бит, булмый һич юктан.
Анда чыңлау!.. Чыңлап
торганны бит
Ясап булмый кызыл балчыктан.

(Балчыктан ул чүлмәк ясап була,
Чүлмәкнең дә була үз чыңы.
Кайсы чакта чүлмәк тавышында
Күмелеп кала чыңның иң чыны.)

Һәр талантның җирдә үз урыны бар,
Һәр телдә бар акыл, моң вә чәм.
«Син Тукайдан өстен!» — дияр идем,
Татар телен әгәр белмәсәм.

1969

Анна Ахматовага*

Бу дөньяда үзеңнеке үз шул...
Ә бит сезне, тугач, иң тәүдә,
Беләм, Анна Андреевна, беләм,
Чукындырганнардыр чиркәүдә.

Безгә исә мулла исем кушкан,
Сәдакасын алып, рәхмәтен,
Нәҗметдинен, Сәйфетдинен кушкан,
Мөхәммәтен яки Әхмәтен...

Ә шул мулла кушкан исемнәрдән,
Яратыпмы әллә, нигәдер,
Фамилиягыз итеп алгансыз сез
Шуларның бер Әхмәт дигәнен.

Заманнарның каһәр чагында да,
Кимсеткәндә кеше кешене,
Теләгәнчә түбәнсеткән чакта
Кайберәүләр безнең ишене,

Тәккәберләр санга сукмаганда
Исем белән хәтта җисемне,
Сез бит, Анна Андреевна, горур
Йөреттегез шушы исемне.

Йөреттегез гомерегез буе
Шагыйрь булып, кеше булып та.
(Шагыйрьлекне, кеше кешелеген
Күреп була күзне йомып та.)

---

* Ахматова — псевдоним. Шагыйрәнең чын фамилиясе Горенко.

Ә бит булды сезне кагучылар
Уяу көе, ачык күз белән.
Кичерегез, хәтта мин дә бер чак
Өрдем, көчек, ихлас күңелдән.

Өрү белән йолдыз сүнәмени?!
(Барысына да, ахры, күндегез...)
Сез үзегез булып яндыгыз да
Һәм үзегез булып сүндегез.

Укытканнар сезгә җеназаны
Сез кушканча, диләр, чиркәүдә.
Кайсы берәү, зур вакыйга итеп,
Салды шуны шигъри үлчәүгә.

Шундамыни сезнең сезлегегез,
Югары бит сезнең инану,
Сезнең алда тигез булгандыр, дим,
Бу дөньяның Әхмәт, Иваны.
Өстенсез сез төрле ваклыклардан,
Ә бит йолдыз янмый түбәндә.
Мин бер якты югарылык күрәм —
Сезне күрәм Шагыйрь дигәндә.

1967

Мәхәббәтнең
килгәнен мин тоям...

Сибгат ХӘКИМГӘ

Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям —
Якыная төсле миңа ул.
Төрле усал, яман карашларны
Өтеп, этеп, җырлап килә ул.

Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям —
Узган язмышларга үч итеп,
Килә кебек, якыная кебек:
«Иң бәхетле итәм үзем», — дип.

Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям —
Тоям аның авыр булырын.
Аткарылмаганнар аткарылыр —
Җан, ниһаять, табар урынын.

Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям —
Ләкин аңа калмам кол булып.
Тормышымның очсыз хыяллары
Очачаклар күккә күл булып.

Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям —
Чигенә кебек артка яшь саны.
Яшьлегемнән кабат килә-килә,
Яшәртермен кебек дөньяны.

Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям —
Үзе килә, килә тирәннән.
Башкодасыз, димләүләрсез килә,
Өстән түгел, килә түбәннән.

Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям —
Язмыш бүләк иткән уттыр ул...
Аһ, җирецнең җирле мәхәббәте!
Шуннан да зур бүләк юктыр ул...

Мәхәббәтнең килерен мин тоям...

1981

Татар акылы

«Татар акылы төштән соң».
Әйтем

Мәңгелек хәл: көннәрнең дә
Иртәсе, төше була.
Аязмы ул, болытлымы, —
Төш аугач, киче була.

Татарның да таңнары бар,
Бар гомер иртәләре.
Әмма кайсы халыкны соң
Язмышы иркәләде?

Кояшлы татар иртәсе!
Каплады сине болыт,
Ябырылды явыз дошман,
Әҗәлгә тиңдәш булып.

Ерткыч талаган кош йоны
Сибелгән кебек җиргә,
Таланып, татар, таралдың,
Сибелдең илдән-илгә.

Дәүләтсез дә, гаскәрсез дә
Калдың син, бөек милләт.
Ә бит дәүләтсез, гаскәрсез
Милләт йә кол, йә үләт.

Ни булды? Үз юлыңа син
Үзең салдыңмы йозак?
Башыңны ашадымы әллә
Үзара булган низаг?

Йөрәгендә сүнмәгән һич
Батырлык дигән ялкын.
Кирәк шул, кирәк «Берлектә —
Тереклек» дигән акыл.

Үткән белән бүгенгедә
Ялганмый торган ара.
Җәбердән һәм хурлыклардан
Йөрәктә канлы яра.

Әйе, булган татарның да
Таңнары, иртәләре...
Җимерелдеме соң бүген
Элекке киртәләре?

Бүген дә кояш чыкты, дип,
Уйланып торам иртән.
Татар акылы төштән соң...
Кайчан төш җитәр икән?

1990

Мөстәкыйльлек

«Убей хоть одного».
Константин СИМОНОВ

(Бу шигъри юллар Ватан сугышының иң авыр көннәрендә язылган «Убей его!» дигән әсәреннән алынды.)

Мөстәкыйльлек — илнең азатлыгы,
Мөстәкыйльлек — җирнең азатлыгы,
Мөстәкыйльлек — тын алганда хәтта
Һаваның хуш исе, татлылыгы.

Мөстәкыйльлек — туган җир-суыңның
Йөрәгеңә үткән тамырлары.
Үзеңнеке хәтта искән җилләр,
Туфрагыңа яуган яңгырлары.

Туган илем, син мөстәкыйль түгел,
Юк бит аны синең тойганың да.
Булды заман — урыс «акылын»да
Тыелды бит сабан туйларың да.

Хөррият, дип шатланабыз бүген
Кайбер нәрсә рөхсәт ителгәнгә
(Әйе, әйе, рөхсәт ителгәнгә).
Милли тойгың, телең үлемечле
Бер чигенә барып төртелгәндә.

Нишләргә соң? Кол итүләр җирдә
Кырылышлы канга манчылганнар.
Азатлыкны яулау да бит әмма
Тора шундый кире алымнардан.

Беләм, халык кан коярга әзер,
Әмма ул юл кискен үлемечле.
Шул юл белән урыс тырнагыннан
Котылулар авыр, үкенечле.

Ә бар бер ул — урысларга, димен,
Безнең хәлне кирәк аңлатырга.
Күпме халыкларга хаким булып
Яшәвеннән хәтта оялтырга.

Аңлатсын, дим, шуны татар, башкорт,
Аңлатсын, дим, чуваш, мари, калмык;
Аңлатсын, дим, коми, бүрәт, хакас,
Аңлатсын, дим, якут, удмурт, кумык.

Аңлатсын, дим, немец, чукча, алтай,
Аңлатсыннар җирдә ирек барын.
Аңлатсыннар чечен, ингуш, балкар —
Бөтен Төньяк Кавказ халыклары.

Аңлатсыннар!.. Аңлатыйкчы! Аңлат!
Хакимлек безне туйдырганын.
Үтер аның каннарына сеңгән
Кара шовинистик тойгыларын.

Аңлат аны милләттәшеңә син,
Аның әле милли горурлыгы
Урыс идәнендә йоклап ята —
Уяту да тормыш хозурлыгы.

Шул тойгыны тик берсеннән алып,
Үтерегез, димен, милләттәшләр!
Шул да җиткән безгә! Ә без күпме
Хокуксызлыктагы бердәмлекләр!

Шул тойгысын аның мин үтерсәм,
Син үтерсәң әгәр, ул үтерсә,
Нигә кирәк безгә кан коюлар.
Әгәр дә ул азат ил китерсә?

О, син хыял! Кайчан илбасарлар
Корбанына ярдәм кулы сузган?!
Шигырьне дә белә торып яздым —
Аптыраганнан бит, чарасыздан.

1992, июнь.

Татар авылында

Даң-доң, даң-доң Мәскәү чиркәү
кага
Телевизор аша.
Шул ук даң-доң радиодан
Урамнарда шаша.

Өйдә даң-доң, урамда да даң-доң,
Котылып кара.
...Әхмәт бабай җомга намазына
Тын гына китеп бара.

1991

Париж өстендә

Казан дәүләт университеты
профессоры Миркасыйм ГОСМАНОВКА

Без Эйфельдә... Уч төбендә кебек
Бөтен Париж — Җир һәм Ил даны.
Әнә Бастилия... Монмартр... Конкорд...
Ә янында Марс яланы.

Париж — тарих... Күпме күкрәү узган,
Күпме исем монда яшьнәгән.
(Парижны да күрми торып, димен,
Моңа кадәр ничек яшәлгән?)

Без биектә... Без — башкорт
һәм татар,
Без зур милләт Париж өчен дә.
— Сөйлә әле, — дидең, — «Татар телен»,
Яңгырасын Париж өстендә.

Без татар һәм башкорт —
кан кардәшләр,
Миндә исә тибә ике кан:
Үзем башкорт, әмма татар теле —
Анам теле миңа тумыштан.

Язык түгел беркем алдында бу,
Туры килгәч язмыш язмышка.
Ә язмышлар «тел, ләгать вә... әхлак»
Бер тамырдан, бер үк сулышта.

Без әле дә бер үк сулыштабыз
Чит бер илдә — француз җирендә,
Ярсып-ярсып шигырь укышабыз
Йә башкорт, йә татар телендә.

Аста Париж... Син уйларың белән
Алып киттең мине Казанга.
Париж түбәсеннән киттең алып,
Бүгенгедән үткән заманга.

Кайдан карарга соң зур Казанның
Ак бүгенен, кара үткәнен —
Сөембикә манарасыннанмы,
Манарасыннанмы әллә
Баумандагы кызыл чиркәүнең?

Юк, карыйк яңа биеклектән —
Син укыткан биек бинадан.
О, университет! Альма-матер,
Күпләр мәшһүр аңа бинаән!

Күз алдында менә
Сөембикә,
Тукай, Җәлил, Ирек мәйданы,
Әнә Болак, Идел, Яңа бистә,
Арча кыры. Печән базары...

Казанда да күпме күкрәү үткән,
Күпме исем балкып яшьнәгән!
Бер уйласаң, Парижны да күрми,
Яшәп булган... ә бит яшәлгән!

Без Эйфельдә — аста кайный
Париж —
Исемендә дөнья тарихы.
Бу мәл Казан ничек кайный икән?
Казан, Казан — татар Парижы!..

1984

Тагын татар...

«Ул вакытта яралардан үлсәм, ичмаса
Туган илем өчен гомеремне биреп үләм дияр идем
Ә менә хәзер эт тормышыннан...»

(Брест крепосте каһарманы Тимерҗан Зиннәтовның
үзенә-үзе кул салу алдыннан язган соңгы хатыннан)

Тагын татар... Гүя Җәлилләрдән
Яшәп килә җирдә тере кан:
Ә бу юлы заман балтасына
Башны куйды карт бер Тимерҗан.

Тагын татар... Урыс җире өчен
Канын койган, җәбер кичергән.
О Брест! Синең коры даның белән
Безме икән коры исергән?

Тагын татар... Туып үскән үзе
Башкортстан дигән дан җирдә.
Рәсәй көчен, урыс хакимлеген
Көчәйтергә киткән Себергә.

Тагын татар... Ана күкрәгеннән
Аерылган кебек нарасый,
Аерылган туган җиреннән ул,
Адашкан җан — милләт баласы.

Себер һәм Брест... Шушы араларда
Тимерҗаннар күпме сибелгән.
Ә нигә соң ул кермәде икән,
Туган җирен ник күрмәде икән,
Барган чакта Брестка Себердән?

Әй син, күңел, ул син синмени соң
Хыял канатында очмаган?

Халкы белән бергә үз сулышын
Алса әгәр, читтә эт тормышын
Күрмәс иде, димен, ичмасам.

Тагын татар! Гүя Җәлилләрдән
Яшәп килә җирдә горур кан.
Ә бу юлы заман балтасына
Башын куйды карт бер батыр җан!

1992

Талант канатында

Дөньяның бөек биючесе
Рудольф НУРИЕВ Париждагы
урыс зиратында җирләнде.

(Хәбәрләрдән.)

Күңелемдә әллә нинди төер...
(Тагын татар — татар ир-аты)
Җирләнде ул урыс зиратында —
Парижда юк татар зираты.

Татаргамы соң ул аерым зират?..
Шулдыр инде язмыш ырыскал:
Хәтта теге дөньяда да татар
Үлеп котыла алмый урыстан.

Аерым зират... Аны да бит мөмкин
Аерым дәүләт диеп атарга.
Татарның чын дәүләте соң кайда,
Аерым дәүләт кайда татарга?

Нуриевтай дөньяда дан тоткан
Шул зиратта тагын кем ята?
Князь Юсуповтыр... Ә җирдә
соң күпме
Данлы урыс биргән ул татар?

Шигырем дә зират тирәсендә
Гел үлгәннәр белән болгана.
Татар — татарлыгын үлеп кенә
Күрсәтәдер, ахры, дөньяда.

Үлеп кенә... Ә соң тере чакта
Кылычмы ул урыс кынында?
Күнеккән бит урыс татарны тик
Күрергә гел иблис сынында.

Ә ул «иблис» япа-ялгыз көе
Урыс богавыннан ычкынып,
Йөремәде читтә хәер сорап,
Париж урамында ышкылып.

Ә очты ул талант канатында
Дөнья сәхнәләрен бер итеп,
Хөр булмаган халкы өчен янып,
Үз язмышын, җанын хөр итеп.

Бер карасаң, ул да кеше, ә бит
Кылган эше шаклар катарлык.
Талант көчеме бу, кан көчеме,
Әллә микән ул көч — татарлык.

Нишләсәң дә үзеңнеке үз шул —
Һәр күңелнең бар үз төяге,
Җанга авыр, хәтта үз кешеңнең
Чит җирләрдә ятса сөяге.

Кайда ятмый татар... Хәтта
кабердә дә
Сагынадыр кебек үз илен.
Шаляпинны урыс үз иленә
Кайтаргандай, татар үз җиренә
Кайтарыр, дим, барыбер үз улын.

Бар җир йөзен хәйран калдырса да
Татар җаны, аның бар моңы.
Бөтен илләр әмма беләме соң
Җир йөзендә татар барлыгын?

Бар өстенә җирдә барлыгыңны
Әйтер өчен бөтен дөньяга,
Нишләргә дип, ярсып Акыл һәм Көч
Тотышалар төсле шобага.

1993

Кәңгеш борылмасы

Химик фәннәр докторы Вил МИРЗАЯНОВны кеше гомеренә афәтле химик матдә эшләп чыгаруны фаш иткән өчен дәүләткә хыянәт итүдә гаепләп маташалар.

Төрмә аша яңгырады кинәт
Аның исеме һәм ул кылган эш.
Үзен күргәнем юк, әмма аның
Туып-үскән авылы, — Тау-Кәңгеш —
Күренеп тора хәтта тәрәзеннән
Минем туып-үскән йортымның.
Шуңа микән, бер горурлык тоеп,
«Дан сиңа»! — дип эчтән укындым.

Төрмә аша... Туры килүме бу?
(Әллә микән җан да саташа)
Безгә генәме ни соң ул гелән
Исме яулау тормыш төпкеленнән
Үлем аша яки төрмә аша.

Агыйделнең Кәңгеш борылмасы
Безнең якта данлы, гүзәл дә.
«Шунда туып үскән ир-егетнең
Бар булмышы нидә?» — дигәндә,
Кәңгеш тавы кискен борган кебек
Агыйделнең алкын агышын,
Ишетте җир кискен борылмалы,
Милләт баласының тавышын.

Купты гауга: галим дәүләт серен
Ача, имеш, — итә хыянәт.
Әй хакыйкать! Бетмәс микәнни ул
Хәтта синнән эзләү җинаять?!

Уйлап торам: чынлап тамы әллә
Хәтәр микән татар кылган эш.
Батырлык бит туфрактан да килә
Горурлансаң да хак, Тау-Кәңгеш!

1993

Татар бугазы

Габдулла БАЙБУРИНГА

Но я
себя
смирял,
становясь
на горло
собственной песне.
В. Маяковский

Башкорт, татар — телләр тәрҗемәсез...
Башкортча бар җырым, моң-сазым.
Татар, башкорт кайда гына юк соң?
Әле менә Татар бугазын
Ярып киләм... теплоходта киләм.
Бер горурлык тоям күңелдә.
Помкапитан якташ: «Саумысыз», — дип
Сәлам бирә татар телендә.

Бер горурлык тойдым — Сахалинда
Башкорт кызы, — таныш кыз миңа,—
Балаларга рус теле укыта
Кинйәбулатова Тәнзилә.

Бугаз дисәң... Җир йөзендә сансыз...
Зуры, бәләкәе... башкасы.
Кайда, дисәң, Татар бугазында
Көнчыгышның Диңгез капкасы.

Сахалиннан материкка Татар
Бугазын мин ярып киләмен.
Палубага түгел,
гүя, үз җырымның
Бугазына басып киләмен.

Әй, басылсын! Хәтта бөеклекнең
Кала җирдә бары беразы.
Үзгәрешле дөнья! Синдә але, димен,
Озак яшәр Татар бугазы.

1977

Ачыну

(Милли зар)

Ай-вай, Сажидә,
Агым суда, басма өстендә
Керләр чайкый сай җирдә.

(Халык җыры)

Бер-беребезгә нинди бәгырьсез без,
Хәтта кансыз — кемнән өйрәндек
Усаллыкка, әдәпсезлекләргә?
Нинди иләк аша иләндек?

Ата-баба гомер юлымы бу —
Без нинди соң, нинди юл алдык?
Аерылдык җирдән, йолалардан,
Үзебездән үзебез югалдык.

Без өйрәндек, әйе, сүгенергә —
Кемнән өйрәнүләр көн кебек.
Өйрәндек без эчеп сугышырга,
Эшләмәскә тирләп, бил бөгеп.

Алла да юк хәзер, мулла да юк —
Милләт һәм тел, җыр, моң буталды.
Үз арбаңда башка җырны җырлау
Тыелмады, хәтта хупланды.

Кая булды олыларны олы,
Кечеләрне кече итүләр.
Кайдан килде ата — улны,
Инә — кызны
Белмәүләргә барып җитүләр?

Адаштылар күңел сукмаклары,
Ябырылгач җанга көллесе.
Күңел ятмаганны үз итеп бит
Яшәдек без, адәм көлкесе!

Көлке генәме соң? Фаҗига бу!
Безнең башка төшкән фаҗига.
Заман керен чайкап булса икән
Чайкагандай керең Саҗидә.

1990

Татар хатын-кызлары

(Көйсез шигырь)

Дан, дип микән, кан, дип микән
Кылыргамы сезгә дога?
Татарларны кем соң, сез бит
Китердегез бу дөньяга,
Татар хатын-кызлары.

Сез бит уңган, дәртле, сылу,
Эшчән булып яралганнар,
Җир йөзенә, халкыгыздай
Сибелгәннәр, таралганнар,
Татар хатын-кызлары.

Язмышмы ул, фаҗигаме
Сез күргәннәр, кичергәннәр?
Сез түгелме
Урысларга — урыс,
Үзбәкләргә — үзбәк,
Казакъларга — казакъ,
Кыргызларга — кыргыз
(Тик бер мисал — Чыңгыз*)
Тудырганнар, үстергәннәр,
Татар хатын-кызлары.

Язмышмы бу, фаҗигаме?

1991

---

* Мәшһүр Чыңгыз Айтматовның әнисе татар кызы.

Торналар

Торналарның да сөйләшкән
Телләре төрле-төрле.
Безнеңчә ул: «Торыйк-торыйкъ!»
Ә урысча: «Курлы, курлы»...

«Торыйк-торыйкъ!», — дип,
китәләр
Күзгә моңлы һаваларда.
«Торыйк-торыйкъ!» — дип,
кайталар —
Шул ук җыр торналарда.

Без ауганмы, без ятканмы —
Нигә соң «Торыйк-торыйкъ!»?
Без гомергә йоклаганмы?
Нигә соң «Торыйк-торыйкъ!»?

Кемнәр өчен бу чакыру —
Безгәме, башкагамы?
Мыскыллы ауган, егылган
Пар ата-бабагамы?

«Торыйк-торыйкъ!»... Кем
аңласын?!
Дөньялар кырлы-кырлы
Торналар да «Торыйкъ!» түгел,
Хәзер бит «курлы-курлы».

1984

Татар генераллары

Татарның ардаклы улы гаскәр (армия) генералы М. Ә. Гәрәев бөтен татар генералларының һәм адмиралларының бер җыелышын оештырды. Алар 28 икән.
(Гәзит хәбәрләреннән)

Бер карасаң, сез халыкның,
Милләтнең горурлыгы.
Үз кешесендә күренә
Халык булдыклылыгы.

Булдыклы һәрчак булдыклы
Йортта да, хезмәттә дә.
Булдыклының эше башка
Фәндә дә, сәнгатьтә дә.

Ә сездә гаскәри сәнгать,
Гаскәри булдыклылык,
Сезнең кылганны тормышта
Гаскәрсез булмый кылып.

Бардыр генералларның да
Гаскәрсез булганнары.
Гаскәрләрегез кайда соң,
Татар генераллары?!

1994

Яшьтәш

Шагыйрь Равил Фәйзуллинның әтисенә

Габдрахман!
Берничә ел моннан әлек кенә
Олуг шагыйрь — синең малаең
Әйтә салды: минем әтиемә
Яшьтәшсең бит, Нәҗар агаем.

Дертләп киттем... Ни әйтергә белми
Мин югалып калдым — кит инде!..
Мин тәү тапкыр шулчак — шул сәгатьтә
Картлыгымны тойдым шикелле.

Күз каршымда ир уртасы — Шагыйрь,
Ә Шагыйре нинди?! Чын-чыны!
Шигърияттә үз корыма тиңләп,
Якын күреп шигъри һәм чынын
Яшәгәнгә микән, әллә микән
Булганга без Шигырь баласы
Җуелган да, югалган да куйган
Яшь арасы, еллар арасы.

Җуелсын да ара, югалсын да
Иң тәүдә без ата-анадан.
Ходайдан бер затлы бүләк булып,
Туа шагыйрь, туа яңадан.

Ходайлыкны Ходай сезгә дә, дим,
Җәлләмәгән — сез дә маһирлар.
Ә язмыйни шигырь язмыйча да
Олы җанлы җаннар — Шагыйрьләр!

Без икәүбез, яшьтәш — ике ата,
Ә мин исә шигырь азгыны.
Кайсыбыз соң безнең бәхетлерәк,
Синме? Минме — шигырь язганы?

Син бәхетле! Миннән бәхетлерәк!
(Юктыр монда акыл сатасы.)
Ата булу һәр ир-атка насыйп...
Син Шагыйрьгә ата! Шагыйрь атасы!

Әгәр Шагыйрь үз картлыгын тойса,
Шагыйрьлеге аның икеле.
Малаеңа илле! Мин тәү тапкыр
Картлыгымны тойдым шикелле...

1993, декабрь.

Мескен бүрек

Мескен бүрек... Нигә икән
Аңа шулай дигәннәр?
Әллә микән аны, димен,
Гел мескеннәр кигәннәр.

Бала чагым. Ул һаман да
Еллар һәм юллар аша
Арттан ияреп килә дә
Күз алларыма баса:

Киндер күлмәк, ялан тәпи —
Мин коеп куйган кебек.
Башымда мескен әтидән
Калган шул мескен бүрек.

Ә ул күптән минем белән
Мәңгегә саубуллашты —
Хәтта кама бүрекләр дә
Бизәде минем башны.

Әмма ни кылсам да, әшем
Пешеп бетмәде кебек.
Гомер буе мескен бүрек
Баштан төшмәде кебек.

1986

* * *

Рөстәм ЯХИН үлеменә

Беләм, берчак һәйкәл куелачак
Композитор Рөстәм Яхинга:
Сәйдәштән соң бөек татар моңы
Хакименә, бөек хакимгә,

Басып торырмы ул, утырыпмы
Бронза Рөстәм гранит ташында.
Ә ул һәйкәл, бар һәйкәлләр кебек,
Тып-тын торыр халкы каршында.

Андый һәйкәл аңа һәйкәл түгел...
Хыялымда куям мин аны:
Илаһи моң бронза Яхиннан да
Чыңлап торсын бизәп дөньяны!

1995

Казанның татар зиратында

Шунда тамсын күз яшемнең
Иң ачы һәм татлысы.
Г. Тукай

Шушы сүзләрне укыдым
Мин кабер ташларыннан,
Алар уелган шикелле
Әче күз яшьләреннән.

Шагыйрь һәм кеше күңеле
Эреп коелган бергә.
Шагыйрь сүзләрен ябынып
Яталар төсле гүргә.

Әй язмыш, шагыйрь язмышы —
Кешеләр бәгырендә!
Сүзләр көчсез — бер сүз дә юк
Шагыйрьнең каберендә.

Тик анда тере чәчкәләр,
Ташында көн яктысы.
«Шунда тамсын күз яшемнең
Иң ачы һәм татлысы».

1951—1983

Диненә карап

Совет иле шаулап бәйрәм итте
Мең еллыгын урыс диненең.
Бу дөньяда диненә бит карап,
Белеп була кемнең кемлеген.

Ата-бабам ислам динен тоткан —
Канга, аңга сеңгән барысы:
Теге дөнья белән куркытуы,
Куркыткан ул — ни хәл итәсең...

Ә бар диннәр Иерусалимнан бит,
Шуннан килгән — башы бер булган.
Тик тәресез, чукынмавы белән
Аерылып торган мөселман.

Вәгазь иткән ислам әдәплелек,
Инсафлыкка барган, өйрәткән.
Таләп иткән кешеләрдән хак сүз,
Талап иткән таза җан һәм тән.

Күп нәрсәне алдан күрә белгән,
Каты булгач сүзе, законы.
Күпме гасыр элек аракыны
Хәрәм дигән — җиткән акылы!

Җиткән! — очрашканда, күрешкәндә
Ислам телендә һәркем
Бер-берсен тәбрик итешәләр
Әссәламәгаләйкүм!*

О, син акыллылык...

1988

---

* Гарәпчә. Татарча: «Сезгә тынычлык булсын!»

* * *

Хәсән ТУФАНГА

Торып-торып искә төшә
Йөрәктә әрнү, сагыш.
Картаеп, аның янына
Әкренләп китеп барыш.

Җир астыннан юл юк, беләм,
Юл да табармын кебек.
Үлгәч, мин аның янына
Юллап барырмын кебек.

1992

Күз яше фонтаны

«Фонтан любви, фонтан печали...»
А. Пушкин

Бакчасарай... Кайчандыр бит үзе
Сарай һәм дә бакча булган ул.
Татар ханлыгында ул нурланып
Балкып та гына торган, торган ул.

Әй, язмышның каһәр кылмышлары:
Канлы җиңелүләр, җиңүләр.
Кыйралышты, тар-мар ителеште
Тантаналы мыскыл итүләр.

Бүген дә мин шул мыскылны күрәм:
Сарай өнсез, рухи хәрабә.
Гүя, ханның бар шөгыле гарем...
Ир куенына керер өчен, гүя,
Хатыннары тота жирәбә...

Монда бүген урыс хакимлеге
Аңкып тора һәрбер диварда.
Әби патша белән Потемкинның
Зина кылып яткан диван да
Төп комартхы булып урын алган...
Пушкин булган монда — вакыйга!
Ул да татарны гел канкойдыргыч
Халык иткән — һаман вак көйгә.

Әмма фонтан урыс йөрәген дә
Тетрәткән һәм шигырь яздырган.
Димәк, татар яу чаба да белгән,
Сөя белгән — эз дә калдырган.

Фонтан, фонтан!
Һаман Кырым өчен
Тартыш бара ике арада.
Алар өчен татар бар ни, юк ни...
Күз яшьләре һаман тамалар.

Фонтан елый...

1993

* * *

Бер-береңнән үрнәк алышулар,
Өйрәнүләр хас һәр халыкка.
Яман ләкин шушы яхшы йола
Салынса бер гомум калыпка.

Һәрбер халык җирдә яшәү өчен
Үз ысулын тапкан. Табылган!
Чабатаны да бит, хәтта, чабатаны
Урыс үрә башлый үкчәдән,
Татар — башыннан.

1988

Хәтерләү

Гамир НАСРЫЙГА

Кая барма — үткән искә төшә,
Ә үткәннәр ерак калалар.
Шулай инде — гомер узган саен,
Хәтерләүләр арта баралар.

Артсын әйдә... Ләкин алда хыял,
Күпме өмет барыр юл сала.
Алда — хыял... Артта —
хәтерләүләр...

Кеше яши шушы уртада.
Ирексездән сине хәтерлим мин,
Караш салам диңгез иңенә.
Ул кемнәрне генә кочмаган соң,

Тик оныткан сине, мине дә.
Без утырган ташны дулкын
кага,
Таш бирешми дулкын какса да.
Ташлар озак яши, йә шомарып,

Йә мүкләнеп-нитеп булса да.
Мәңгелеккә килмәгәнмен мин дә,
Вакыт үтә — булмый баш булып;
Ташлар озак яши... Ярый әле,
Яратылмаганбыз таш булып.

1963

Кәккүк тавышы

Габәши каберен эзләп,
Тимер Арслан белән
Без зыяратта йөрибез...
Тирә-як — ямь-яшь үлән...

Еллар, еллар... Без окоплар
Казыдык җирдә ул чак.
Ә монда бер чит кешегә
Кабер казыган Чалкак*.

Һәр кабер — җирнең ярасы,
Ябылмый торган яра.
Кайда соң ул? Кешедән бит
Кабер булса да кала?!

«Кайда?» — дип эзләп, сорап,
Йөрибез урап-урап...
Чү! Янәш кәккүк чакыра,
Елларны санап-санап.
Ул чакырмый, ул моңлана
Татарча, башкортчалап.

Әй, ул моң, җыр якын кебек
Тик безгә, безгә генә.
Хуш, Чалкак!.. Кәккүк тавышы
Үзәкне өзә генә.

1971

---

* «Кәккүк» дигән мәшһүр җырның авторы композитор Солтан Габәши Борай районы Чалкак авылында күмелгән.

* * *

Михаил ЛЬВОВКА

Татарлардан урыска әйләнгәннәр,—
Гасырларга керсәң,— күп инде.
Бөек Идел бөек Волга булып
Безнең көндә аккан шикелле.

Тарих өчен кечкенә бер мизгел
Бер кешенең гомере, базары.
Күз алдында рус шагыйре булды
Нәсибашның* гади татары.

Рус шагыйре... Хәтта руска авыр
Шундый булу, шуңа ирешү.
Ул кылганның кемдер Россиядә
Кыла алыр микән киресен?

1986

* Нәсибаш — Башкортстан АССРның Салават районындагы шагыйрь туган авыл.

* * *

Дуртөйле районы Йобанай
авылы татар мәктәбе альбомына

Туган җир-су — үзе бөек мәктәп,
Шул җирдә бит тәпи басыла.
Һәркемдә тел — бөек ана теле
Ана сөте белән ачыла.

Тормыш кебек төрле дәресләрдән,
Сынаулардан тора һәр мәктәп.
Дәвам итсен дәрес — Туган илгә,
Туган телгә булган мәхәббәт.

1988

Өч тел

Беренчесе — анам теле —
Җирем, һавам, каным теле
Гомер буе кешеләргә
Мәхәббәтле итте мине.

Икенчесе керде аз-маз
Ерак коръән битләреннән.
Салды курку, итте азат
Фани дөнья чүпләреннән.

Өченчесе фән, мәгърифәт
Дөньясына ачты киң юл.
Бернәрсәсен җәлләмәде,
Барсына да өйрәтте ул.

Нигә шулай?

«Я хотел бы жить и умереть в Париже,
Если б не было такой земли — Москва».
В. Маяковский

Минем туган илем булган кебек,
Урысның да туган иле бар.
Күп җирләрне яулап, буйсындырып,
Корган дәүләте бар, теле бар.

Барсы да бар... Ә соң нәрсә җитми,
Нәрсә җитми икән урыска?
Үз Россиясе бит — киң дә, зур да —
Аласы юк берни бурычка.

Барсы да бар, ник ул ташлап китә
Ата-баба җирен, йорт-илен:
Владимирын һәм Вологдасын,
Новгородын яки Тверен?

Ташлап китә иген иккән кырын:
Авыллар буш, өйләр шәп-шәрә.
Кем икмәген ашар өчен китә,
Үзен-үзе итеп мәсхәрә?

Илен ташлап ул Парижга китә,
Барып чыга океан артына.
Тик телен һәм холкын тага алмый
Шул илләр һәм җирләр халкына.

Илен ташлап Латвиягә керә,
Тормыш көтә Литва җирендә.
Исе китми яши бирә казакъ,
Үзбәк, татар, башкорт илендә.

Нигә шулай? Кайда үз җиреңә,
Тарихыңа булган мәхәббәт?
Нигә кирәк бутау кеше йортын,
Үзеңнеке итеп исәпләп?

Туган җирең — атаң-бабаң жире,
Тәнгә, канга сеңгән җир-суың.
Үзе зур бәхет бит аның — ул син,
Синең — тик ул, тик ул булуың.

Шул бәхеттән мәхрүм булудан да
Бәхетсезлек юктыр. Юк ул, юк!
Чит җирләрдә хәтта хайван җирси,
Тик кешегә хасмы алйотлык?

Вологдалар, Новгородлар миңа
Ят җир, ят моң, ят тел, ят холык.
Хәтта Мәскәү якын тоелса да,
Эшләсә дә миңа яхшылык,
Ул барыбер Уфа, Казан түгел,
Үз бармагы үзенә кәкере;
Нишләтсәң дә, бер тамырдан түгел
Минем бәгырь, аның бәгыре.

Әй китәләр... Азат тормыш эзләп,
Байлык эзләп әллә кайларга.
Азатлыкны да бит, байлыкны да
Үз илеңдә кирәк яуларга.

Үз илем бар, бар үз һавам, телем —
Йөрәк каным миңа бу аһәң.
Россиядә яшәп, үләр идем,
Башкортстаным, син булмасаң.

1989

Мичкә

«Смирись, Кавказ: идет Ермолов»
А. Пушкин.

Бүген урысча язалар,—
Гәзитләрдә шомлы аваз,—
Дары мичкәсе өстендә
Утыра, дип, Төньяк Кавказ.

Ул мичкәне кем китергән,
Кем куйган соң монда аны?
Ермоловлар!.. Ә ул кемнең,
Кайсы халык генералы?

Гасыр ярым тора мичкә,
Күпме афәт торышында.
Башкалардан өстен булу —
Колонистлар рухында.

Ул рух хәтта Пушкинда бар,
Бар Лермонтов сулышында.
Чеченнәргә һөҗүм иткән
Ул да Кавказ сугышында.

Гасыр ярым тора мичкә
Карлы таулар җилкәсендә.
Даны шартлый җиңүченең
Бүген хурлык мичкәсендә.

Соклансам да чеченнәргә,
Җыенмыймын шаккатырга.
Иреклек бит чакма-очкын
Шул мичкәне шартлатырга.

Ул мичкә тора Казанда
(Ул дүрт гасыр инде тора).
Мичкә шартламасын өчен
Хуҗа төрле хәйлә кора.

Шул мичкәне шартлатмаска
Төрле битлек каплый бит ул.
Аны хәтта халыкларның
Дуслыгы дип атый бит ул.

Дуслык булган һәм булачак
Мичкәсез дә, дарысыз да.
...Таулыларның батырлыгы
Үрнәк булсын барыбызга.

1993

* * *

Урысны кырып карасаң, диләр,
Шуннан гелән татар калкып чыга.
Яшь татарны кырып торасы юк,
Аннан бүген урыс аңкып тора.

1994

* * *

Көч булганда акыл кирәкми, дип
Әйткән урыс — чыккан сугышка.
Килде заман. Көч куллану бетте!
Нишләргә соң хәзер урыска?

1994

Бүгенге тәфтиләүләр

Үткәннәрдән чыңлап килә
Ерткычлык, әзәрләүләр;
Килә каргыш җыры булып,
Тевкелев — тәфтиләүләр,

Денен һәм иманны сатып,
Чукынып урысларга,
Үз бәхетен тапкан алар
Күз-яшь, кан коешларда.

Һәр заманның — ах, кызганыч! —
Бар үз тәфтиләүләре.
Аларны аңлавы җиңел,
Читен тәфсилләүләре.

Узган замандагыларның
Кулында гаскәр, корал,
Аларга корал ясарга
Байлыгын биргән Урал.

Бүгенгеләрнең коралы —
Вазифа, урын, исем.
Без шундый акыллы башлар —
Уйласаң — китә исең.

Азатлыкны теләнәбез
Булмасын белә торып,
Кыйланабыз урыска һич
Чукынмаганнар булып.

Чукынганнар белән җаным
Бөртек булмады уртак.
Ә иманымны яклап мин
Кермәдем утка — куркак!..
Нәрсәдән икән куркырга —
Дөнья бит үзгәрүчән?
Ә аны җыр язып кына
Үзгәртеп булса икән?!

Шуңадыр ла ялагайлык
Ярыкларына посып,
Хакимнәрнең сәдакасын
Иманга бутап, кушып,
Сәмрүгкошлы тереләрне
Милли җаннарга тагып,
Урыс белән без мәңге дус
Булдык, дип чаңнар кагып,
Кеше аңын томаларга
Без оста булып киттек.
Кап-кара тарихны ап-ак
Җеп белән ямап беттек.

Үзен гел кол итеп тойган,
Азатлык, дип канын койган,
Илдә яу чаба-чаба,
Шушы ялганнан гарьләнеп,
Каберләрендә әйләнеп,
Куядыр ата-баба.

Бүген дә рус үз терәген
Тәфтиләүләрдә күрә.
Төрле-төрле хәйлә корып,

Милләт көрәген тоттырып,
Милләтне көрәттерә.

Тик бер Чечня коя канын,
Үз өстенә алып барын —
Башкалар тора карап.
«Нинди сугыш бу?» — дигәнгә,
Ишетелми беркемнән дә
Ачык һәм дөрес җавап.

Еллар үтә... Кеше күнә...
Әкренләп шым, шып-шым сүнә
Милләтләр, илләр, телләр;
Куркыныч һәм яманрак
Бүгенге тәфтиләүләр.

1996

Гомер сөргәндә

Данлы Брест крепостеның батыры,
ардаклы укытучы
Ришат ИСМӘГЫЙЛЕВКА

Бу дөньяда булгач була икән
Кешеләр дә синең шикелле.
Кирәк икән син бирергә әзер
Кисеп алып йөрәк итеңне.

Изгелеклек башка күрмәсен дип,
Кешеләрнең иле — йортында,
Ходай сине саклап калган кебек
Үтермичә сугыш утында.

Брест... Брест... Сугыш тынган
кебек, ул да
Тынды... Сүнде... Китте кадере.
Кирәк чакта гына микәнни соң
Батырлыклар бездә кадерле??

Синең өчен ул җир башка кавем,
Башка милләт җире, төяге.
Шул төяктә ятадыр ул һаман
Сыңар аягыңның сөяге.

Гомер буе аксак... Адымнарың
Сиңа тугры юлдаш таяклы,
Әмма түгел синең йөрәгең һәм
Кешелегең сыңар аяклы.

Күңеленнең нуры күңелләргә
Изге орлык булып сибелде.
Рәхмәт дигән алтын кирпечләрдән
Сарай салды сиңа Байгилде*.

Сез үстергән уллар, кызларыгыз
Акыллары белән биргән кот.
Алар кайтса, гыйльми бер мәркәзгә
Әйләнә дә куя сезнең йорт.

Күпме шатлык, күпме рәхмәт сүзе,
Күпме сөю һәм нур тирәндә.
Сугыш уты сине аксатса да,
Аксамадың гомер сөргәндә.

1996, апрель

---

*Р. Исмәгыйлевнең укыткан авылы.

ТАТАР КАНЫ

Поэма

Йөрәк каным белән яза-яза,
Теркәп килдем елга елларны.
Ни белән соң мин язарга тиеш
Канга бәйле шушы юлларны?
Кан... Кан... Ул — җан,
йөрәк,
сулыш,
тормыш —
Мөкатдәсләрдән иң мөкатдәс!
(«Кан-җан» — үзе рифма! — ә русларда
Туры килә аңа «мәхәббәт»*.)
Бар изгелек сыны, әйе, ул кан!
Канга бәйле якын туганлык.
(Канкардәшлек мәңге яшәп килгән)
Канга бәйле авыр дошманлык.
Кандошманлык — инде үткән заман,
Алар безгә керми киткәннәр:
Заман җилендә шул җилгәрелеп,
Киләчәккә бара үткәннәр.
Кандошманлык түгел, ә кандуслык
Яши хәзер кеше канында.
Йөрәгемне ярып төшкән җырым
Әнә шундый дуслык хакында;
Ул дуслыкның туган Ватаны бар.
Тирән тамыр җәйгән җире бар.
Ул дуслыкның сүзсез сөйләшерлек
Кан теле бар, йөрәк теле бар.
Шагыйрь диләр мине... Димәк, үзем
Сөйләшә алам каным белән дә,
Кирәк икән бәхәсләшә алам

* «Кровь» — «любовь».

Үз каным һәм җаным белән дә,
Шагыйрь диләр мине... кануннардан
Азат минем гади мәртәбәм.
Мин азатмын алтын йөгәннәрдән,
Мин азатмын алтын тәртәдән.
Әйтерләр: «Бу нигә болай түгел,
Ә тегеләй нигә тегесе?»
Шагыйрьләрдән мотлак күп беләләр
Өстән бакканнарның күбесе.
Шагыйрь диләр мине... хокукым юк
Хакыйкатькә хыянәт итәргә.
Мин бурычлы шушы юлларымны
Шагыйрь намусы белән үтәргә.

I

Китерсәгез икән күз алдына
Сандугачлы җәйге бер таңны,—
Шушы таңның һәрбер минутыннан
Җиргә, җанга чыңлап моң тамды.
Шушы таңның бетмәс хозурлыгы
Йөрәкләргә иде моң — шифа.
Шушы таңда тәү кат ана булды
Татар кызы Зифа, Гөлзифа.
Бала табу йорты. Кошлар белән
Бергә сайрый төсле сабый кыз.
Яшь лейтенант — ата — чик буенда
Икеләтә бүген йокысыз.
Эчтән генә: «Зифа бәгърем, диде,
Котылгандыр инде баладан...»
...Кинәт шартлау... һәм җир
тетрәп куйды,
Гүләү тавышы килде һавадан.
Бар дөньяның асты өскә килде —
Ут эченә керде туар көн.

Тәүге минутта ук чолгап алды
Бөтен тирә-юньне ут-төтен.
«Иван! — диде яшь командир Яхин, —
Приказ түгел, бары үтенәм.
Чап роддомга, зинһар коткара күр
Ана һәм сабыйны үлемнән.
Моннан миңа китүләр юк, солдат,
Хәзер бу җир сугыш яланы.
Озат тылга. Күр, әнә, бомбага
Тота башладылар каланы...»
Чапты Иван! Таңга каршы чапты...
Яна кала. Килсә — ни күрсен! —
Җимерелгән бала табу йорты,
Бала табу йорты ут-төтен.
Ак халатта йә булмаса эчке
Күлмәктәге көе хатыннар
Сабыйларны өч-дүртәрен бергә
Өй эченнән тышка ташыйлар.
Ир тавышы: «Машинага! Җәһәт!»
Кайда Зифа? Йөрде җан атып,
Күрде аны — кан эчендә, һушсыз.
Носилкада. Барды озатып.
Кире чапты Иван. Кире чапты
Командирга хәбәр итәргә.
«Алар тере. Тылга китте», — дигән
Бәхетле сүз — шатлык илтергә.
Килде Иван... Ах! Командир үлек...
Катып калды баскан җирендә.
Сугышның бу тәүге сәгатьләре,
Күнегелмәгән шул үлемгә.

***

Язмыш мине шаһит итмәсә дә
Тәүге сәгатенә сугышның,
Ә Берлинда җаным-тәнем белән
Кичердем мин соңгы минутын.
Тәүге белән соңгы арасында
Миллионлаган язмыш арасында
Геройларым да дүрт исемле.
Ләкин алар болындагы сансыз
Үләннәрнең дүрте шикелле.
Ә берсен бит тәүге минутта ук
Чабып өзде үлем — ут-чалгы.
Бүтәннәре сугыш юлларында
Бер табылып, йә бер югалды.
Һушына килгәч, Гөлзифа да кинәт
Аңламады кайда икәнен.
Тик соңыннан белде тере калган
Сабыйларның ары киткәнен.
Беркөнлекләр, өчкөнлекләргә дә
Сугыш — сугыш иде... Кансызлык...
Зифа — ана, тик баласыз ана,
Күкрәк сөте акты кан булып.
«Кайда бала? Мөмкинме соң тере
Калулары мондый дөньяда?..»
Күңел кошы булып кына калды
Үз сабые безнең Зифага.
Тере калды Зифа... Аһ, ул кеше җаны,
Үлгән җирдән кайта, терелә.
Үлгән, диде тере баласын ул,
Тере, диде үлгән иренә.
Ах, ышану! Ярый әле ул бар!
Ә соң ансыз яшәү мөмкинме?
Зифа — доктор. Яу кырына китте
Ирен эзләп киткән шикелле.

Яу кыры киң. Шушы киңлекләргә
Утлар аша җиргә багу да,
Челпәрәмә килгән бу гомернең
Ватыкларын эзләп табу да
Бәхетләр ул сөйгән йөрәкләргә,
Өмет белән тулы йөрәккә?
Гөлзифага бар дөресне әйтсәң,
Ышанмас ул. Минем күкрәккә
Ятып бер елар да: «Юк! Юк! —дияр,—
Дөнья түгел газап бөтие.
Сөям аны! Мөмкин түгел аның
Мәхәббәтне ташлап китүе!»
Зифам! Зифам! Синең тойгыларга
Кысыласым килми, килми шул!
Үлгән һаман синдә тере көе,
Тере балаң һаман үлгән шул.
Аналык бит сиңа бер күз ачып
Йомган ара гына, Гөлзифа.
Кем уйлаган шушы кыска ара
Булыр диеп сиңа мең җәфа?
Әй укучым, син дә мине кичер —
Язганнарым таныш тоелса.
Китте күрү тормыш, сугышны да
Әзер сценарий буенча.
Мин солдатмын. Һәр солдатның яуда
Үз язмышы һәм үз сугышы.
Сулышлар да ул бертөрле кебек,
Тик үзенчә һәркем сулышы.
Сугыш өчен болар барысы да
Гади тарих, гади күренеш.
Бер карасаң, сугыш тормыш иде,
Гади тормыш — үлем, үтереш.
Гади тормыш иде ышанырлык,
Ышанмаслык хәлләр сугышта.
Менә ялан госпитале... Ул да

Үз тормышы белән тормышча.
Кемнең кулы, кемнең аягы юк,
Кемнең башы, йөзе канлы бинт.
Гөлзифага берәү пышылдады:
«Зифа, это вы? Вы-ы... Бу сез бит!»
(Бөтен йөзе иде канлы бинт).
Ни әйтергә белми катып калды,
Катып калды Зифа... Соңыннан:
«Кем син?» — диде аңа. Әмма солдат
Язган иде инде һушыннан.
(Әй син, тормыш, язмыш!.. Менә әле
Бу юлларны язган чагымда,
Телевизор аша, сыер савучы ир —
Яп-яшь бер ир туган ягымнан
Карый миңа. «Хезмәт даны» дигән
Өч орденлы. Карый һәр йортта.
Әй заманнар! Герой булып була
Безнең көндә сыер савып та.
Ә лейтенант? Минем яшь командир?
Кайда аңа дан һәм батырлык?
Хәбәре дә хәтта килмәде бит
Ил-җирендә балкып ятырлык.)
«Кем ул,— диде Зифа.— Юк,
ул түгел,
Тавышы да түгел tanырлык».
Шул вакытта хирург: «Кан! Кан! — диде,—
Каны беткән аның, каны юк!»
Солдат белән янәш ятты Зифа —
Тәннән тәнгә күчә, күчә кан.
Әй гомернең бөек минутлары!
Тәннән тәнгә күчә, күчә җан.
Мине шагыйрь диләр... Бу минутта
Көчсездер ул хәтта шагыйрьлек.
Табалмамдыр канлы сүзләрне мин
Канлы шигырь яза алырлык.

Җир өстеннән гүя юар өчен
Газапларын сугыш кырының,
Гомер булып рус егетенә
Каны кирә татар кызының.
Нәрсә соң бу? Әйе, гадәти хәл,
Гадәти хәл тәүге күрүдә:
Бер уйласаң, гадәти бит җирдә
Бала табу — гомер бирү дә.
Ә соң анда күпме бөеклек бар —
Кеше туу — нинди бөеклек!
Шушы бөеклекне кыйратырга
Туган сугыш — нинди киеклек!
Кыйралышта күпме корал һәм ут,
Ә ут сүнә кеше тәнендә,
Үз акылы алдында бит адәм
Кала үзе бөҗәк хәлендә.
Ә син, адәм! Синең бөеклегең
Вәхшилеккә, гүя, юл суза.
Вәхшилекне каны белән җиңәр
Өчен дә шул ята Гөлзифа;
Яралыга аның каны кирә,
Ул кан исә яшәр юл кебек.
Үзенең дә гомере — бу сугыш бит! —
Өзелергә торган кыл кебек.
Бүген син бар, ә иртәгә инде,
Ә иртәгә инде... Кем белә...
Әмма исән калырмын, дип яуда
Өметләнми кемнәр? Кем генә?
Бүген монда, ә син уйламыйсың
Барыр юлың күпме калды дип.
...Озатып калды яралылар белән
Киткән Гөлзифаны алгы чик.
Тәүге сәгать үк эшелонга килеп
Ябырылды соры юнкерслар.
«Воздух!» — диде Зифа һәм

кычкырды:
«Лэгънэт сезгэ, һай, кан эчкечлэр!
Нишлисез сез? Монда яралылар,
Яралылар монда баралар.
«Бобах!» Бобах!» Бомба...
Ишетелеп калды:
«Доктор! Доктор!»... шартлау аралаш.
Кан эчендэ җирдэ ята Зифа,
Ала Зифа соңгы сулышын...
Үлмэ, Зифа, зинһар, үлэ күрмэ,
Башлана гына синең тормышың!
Үлмэ, Зифа, синең кызың тере,
Болай да бит бала атасыз,
Нигэ тагы ул калырга тиеш,
Ул калырга тиеш анасыз?
Зифа өчен кан коелыш бетте...
Яңак буйлап каны йөгергэн.
Кичэ —
Каны белэн гомер биргэн иде,
Бүген — язды үзе гомердэн.

II

Госпитальдэ дэ бит тормыш — тормыш...
Кызык инде солдат гомере.
Буген һушсыз, э иртэгэ дисэң —
Күтэренке аның күңеле.
«Иван! — дилэр.— Бие, сиңа бүлэк!
Түбэң синең күккэ тиячэк».
«Аяк юк»,— ди Иван. Э тегелэр:
«Сиңа шуннан аяк үсэчэк».
«Хэл керсен,— ди Иван,— биергэ ул
Мин риза хэтта баш белэн».
«Да!.. Ха-ха-ха! Кем биемэс икэн
Менэ шундый кара каш белэн!»

Күреп тора Иван: фотосурәт...
«Каңгыртмагыз, нинди бүләк ул?»
«Хирург бирде. Сиңа гомер биргән,
Үзе һәлак булган йөрәк ул».
Алды Иван. Карап катты Иван...
Күзләреннән мөлдерәп яшь ага.
Караштылар дуслар. Менә сиңа
Көлке, диештеләр үзара.
Елый Иван, үксеп-үксеп елый,
(Ни әйтергә моңа карата).
Иван белән бергә елый әле
«Ха-ха!» — дигән бөтен палата.
Нинди халык соң бу? Аңлап кара
Аның җанын, холкын, сулышын.
Ничек итеп Гитлер шул халыкны
Кол итмәкче булган икән соң?

III

Яу кырында яраланып, тере
Калу үзе бәхет саналды.
Ул бәхеткә бөтен үткәннәр һәм
Бар киләчәк килеп ялганды.
Бәхетне дә, бәхетсезлекне дә
Ялгый-ялгый еллар үттеләр.
Ә ул еллар киләчәкләрне дә
Ага-ага үткән иттеләр.
Хәзер инде, сугыш елларыннан
Ераклашкан саен аралар,
Яуда үлүләр дә тирән эзле,
Тирәнәя алган яралар.
Ул яралар безнең Иванда да
Калмадылар алган көенчә.
Иван язмышы соң ничек, дисәк,
Һәркемнең ул һәрчак үзенчә.

Ә шулай да кем соң әле Иван?
Ә кирәкме аның кемлеге?
Суздаль ягындагы бер авылда
Кырыктылар аның кендеген.
Буе-сыны, төсе-башы белән
Коеп куйган саф рус егете.
Андыйларга бик тиз багланыла
Кыз-кыркыннарның да өмете.
Армиягә алгач, юллар аны
Китерделәр илнең чигенә.
Ул Яхинга ординарец булды,
Командирга — Зифа иренә.
Ә аннан соң?.. Утлы өерменең
Безгә таныш бөтен михнәте.
...Кайтты Иван култык таягында,
Ә кесәдә Зифа сурәте.
Ике тәрәз арасында, түрдә
Тора Зифа — күзләр нур чәчә.
Татар кызы — почмактагы тәре,
Мәрьям-ана белән янәшә.
Ике ана — берсе легендадан —
Алланың бит үзен тудырган.
Икенчесе — ике гомер биреп,
Һәлак булган сугыш кырында.
Карлыгачның пар канаты — кашлар,
Өтеп ала торган карашлар.
Шул караштa төйнәлгәндер төсле
Төрле язмыш, төрле тарафлар.
Кергән, чыккан һәркем Гөлзифаны
«Чегән кызы бит бу!» диделәр.
Иванның да озак өйләнмәвен
Гөлзифадан гына күрделәр.
Ә кем белә, бәлки, биргәндер ул
Иванга көч, дәрман, сабырлык.
Мәрьям-анадан да көчлерәктер

Мәрхәмәтлелек һәм матурлык.
«Өйләнүләр качмас,— диде Иван,—
Кирәк әле башта җиңәргә.
Киләчәкләр бүгенгедәй булмас,
Ә хәзергә сыер җигәргә...»
Килде Җиңү! Еллар... Институт...
Әйтте Иван: «Кайтам — җан куша!»
Иван белән килен булып төште
Кала кызы Марфа, Марфуша,
Зифаны тәү күргәч, яшь Марфада
Томанлы бер зур шик ярaлды.
Тик язмышын кире сөйләп биргәч,
Күңелдәге томан таралды.
«Нигә Зифа кызына,— ди Марфа,—
Син ата, мин ана түгелмен?»
(Яшь Марфада авыр түгел күрү
Булачак яшь ана күңелен.)
Бу сораудан өзгәләнде Иван:
«Кайдан миндә шундый гамьсезлек?
Бу түгелме,— диде,— үз жаныңа,
Үз каныңа булган кансызлык?»
Әйтеп куйды: «Ул баланы табу —
Хыял эчендәге хыяллар.
Ә түгелме Зифа туганнары
Минем белән синең туганнар?
Ник шуларны эзләмәскә безгә?
Туганнары бардыр...» Бар ул, бар!
Кайда алар? Ә бит җир йөзе киң,
Кайда да бит яши татарлар?!
Бөтенесе өскә бәреп чыкты,
Тынычлыгы качты Иванның.
«Мин табарга тиеш,— диде эчтән,—
Туганнарын минем дөньямның.
Тусак та без төрле-төрле җирдә,
Без бит бер кан хәзер — без бер кан!»

О туганлык! О мәхәббәт уты!
Сүнүләр юк, син бер кабынсаң!
Китте хатлар бөтен илне иңләп...
Язам,— дисәм,— барын җентекләп,
Мәрхәмәтле бу газабы аның
Булыр иде үзе бер китап.
Җентекләүгә проза бурычлыдыр,
Поэмага ул бер кан дошман.
Күпме билгесезлек, күпме серләр
Ачылмыйча кала сугыштан.
Кайда татар — шунда хатлар китте...
Юлын тапты Казан, Уфаның,
Ленинградта йә Мәскәүдәдер
Туганнары, диде Зифаның.
Язды Әстерханга, Сарытауга,
Ырынбурга, Пермь, Пензага,
Чиләбегә, Рязань, Свирлауга...
Булырмы ул, булмасмы дип һәркөн
Тотты кебек Иван шобага.
Кай җирләргә генә бармады ул
Өнсез яткан хатлар эзеннән.
Түмән, Тубыл буйларына барып,
Урап кайтты ерак Себердән.
Кайда татар — уе шунда китте,
Өтте аны хәтер-яралар.
Тик Марфуша әйтте: Русь җирен
Ничек басып алган татарлар.
Күңеле белән Марфа беркатлы шул,
Тик елмаеп куйды Ванюша:
«Миндә татар каны, мине дәме
Татар басып алган, Марфуша?»
«Синдә татар каны,— диде Марфа,—
Синдә татар каны! Ха-ха-ха!
Болай булгач, чынлап, Иван җаным,
Син татарник Иван лабаса!»

«Күлмә, Марфа!.. Аера бел син дә
Дөреслектән бөтен ялганны!
Татар каны бизәп һәм гүзәлләп
Тормыймыни Кызыл мәйданны?»
Аңламады Марфа: «Кан һәм бизәү...
Нинди була ул кан бизәве?
Җиргә тамган кан ул карая бит,
Кара тап соң матур, гүзәлме?»
Әйтте Иван: «Димәк, кара түгел,
Храм* бит балкый Кремль янында,
Бөек җиңү истәлеге булып
Басып тора татар канында.
Ә ул чәчәк бәйләмедәй гүзәл
(Татарник та үзчән бер чәчкә).
Тарих тарих булып калсын, аңа
Киңәш бирер идем тимәскә».
«Тарих — тарих та ул,— диде Марфа,—
Җуеп булмый барын — хәтер бар.
Үткәннәргә ничек карыйлардыр
Синең кебек татар канлылар?»
«Юк, мин рус бит,— диде
Иван,— мин рус!
Коткарса да ул кан үлемнән.
Рухыбыз бар, данлы халкыбыз бар,
Мөмкин түгел китү үзеңнән.
Тарихыбыз һәм халкыбыз данлы,
Җиңеп чыккан һәрбер сугыштан.
Һәрбер җиңү, яулап алган җирләр
Тик Рус дәүләтен бит ныгыткан».
«Безнең заманда да үз дәүләтен
Ныгытырга, Ваня, бик теләп,
Синең кебекләрне — күпме корбан! —

* Сүз Василий Блаженный храмы турында бара.

Кул-аяксыз итте бер үләт.
Ныгытулар булсын иде һәрчак
Җирдә берни кырмый, яндырмый,
Башкаларны җирсез, моңсыз, телсез,
Кул-аяксыз, сукыр калдырмый».
«Син, Марфуша, шәйләп! Киңәш бирәм
Мәсьәләгә тирән кермәскә.
Татарник бит чәнечкеле чәчкә,
Кирәктер ул аңа тимәскә!»
Иван! Иван! Нигә «шәйләп!» — дисең,
Марфага син, зинһар, шик салма.
Шуннан да зур бәхетсезлек юктыр,
Эшең, уең булса ясалма.
Ваня! Ваня! Шагыйрь диләр миңа,
Күкрәп була бары яшьнәсәң.
Ни мәгънәсе бардыр шагыйрьлекнең
Әгәр дә гел шәйләп яшәсәң?
Шагыйрь диләр миңа. Мин иң тәүдә,
Мин иң тәүдә, димәк, миллимен.
Милләтем һәм халкым белән генә
Мин шагыйрьмен, Туган иллемен.
Һәр халыкның, һәр милләтнең җирдә
Үз тамыры һәм үз кәүсәсе
(Кеше бөек акыл, җаны белән,
Бөек итми аны гәүдәсе).
Ул ботак та, ул яфрак та түгел.
(Көмеш, диләр, суда эремәс!)
Ботак кебек бик тиз корымас та,
Яфрак кебек коелып черемәс.
Кайберәүләр әйтә: үткәннәргә
Керү нигә — буш һәм вакытсыз.
Аларча бит яшәп була хәтта
Милләтсез һәм туган халыксыз.
Ваня! Марфа! Ә сез андый түгел —
Үткәнеңне кирәк белергә.

Халкың белән горурлану — ул дан!
Тик кирәкми аны (нигә ул сан?)
Зурга, бәләкәйгә бүлергә?
Марфа! Марфа! Син гаепле түгел,
Әгәр синдә булса хаталар.
Рус җирен бит, җаным, беркайчан да
Басып алмадылар татарлар.
Канын татар койса койды бары
Саклап илен, туган җир-суын.
Бүген исә дуслык каны тибә
Ирең йөрәгендә, сылуым.

IV

Тырышканда мөмкин булган кебек
Ташларга да кадак кагарга,
Печән кибәненнән энәне дә
Мөмкиндер ул эзләп табарга.
Күңелемдә янган тойгыларым
Түгелдер ул ким дә, артык та,
Дертләп китте Иван: журнал бите —
Детдом балалары «Артек»та.
Әй елмая, әй елмая шуннан
Бер кыз бала карап Иванга.
«Таптым! — диде.— Һәй! Эврика!
Марфа!» —
Сикереп торды Иван диваннан.
Әй елмая бала... Көләч иде
Командиры — Зифа ире дә:
Командирга суеп каплаган бит —
Охшап тора бөтен җире дә.
Мәрхәмәтле йөрәк тибешләре,
Сез бар чакта минем җырым да
Канлы кебек һәм канатлы кебек...
...Очты җәһәт Иван Кырымга.

Очмаслыкмы? Ниндидер көч, тою
Керәдер ул кеше канына.
Кыз бала да чакыра кебек иде:
«Кил! — дип,— кил! — дип,—
минем яныма.
Әй чакыру! Күңел чакыруы!
Каршы килү аңа мөмкинме?
Табылырмы, юкмы? Нинди детдом?
Ә кыз бала шулмы, түгелме?
Менә диңгез... Безнең Иван исә
Йә тегендә чапты, йә монда.
Кешеләрне язмыш йөртә, диләр,
Язмыш иде бала — Иванга.
Менә, менә ябылырлар кебек
Йөрәктәге бөтен яралар.
Белде Иван: Мәскәү детдомыннан
Килгән икән теге балалар.
Кызның кайдан, кем икәнен белгәч,
Батты Иван авыр уйларга.
Язмышлардан узмыш юк ул, диләр,
Кем уйламый аны узарга.
Шуңадыр да: «Үзен күрәм! — диде,—
Шайтан гына, диләр, өметсез:
Мәскәү бөек, мәрхәмәтле мәркәз
Ул мине дә итмәс бәхетсез».
Кызыл мәйдан аша ул җитәкләп
Үтәр кебек иде шул кызны.
Мәйдан аша үтеп бара Иван...
Үтеп бара... Әмма ялгызы.
Бу мәйданда бөтенесе изге —
Тарих монда аның һәр ташы.
Тора монда тугыз башлы храм —
Мин, дигәндәй, җиңү патшасы.
Бу мәйданда бөтен нәрсә изге,
Шуларга без инде өйрәнгән.

Монда күпме гомер һәм язмышлар
Бер төенгә килеп төйнәлгән.
Бу мәйданда бөтенесе изге,
Ята кебек һәр таш уйланып,
Русь бу! Бу рус җире! Һәр сулышы
Иманына яши инанып.
Әмма монда, барсыннан да башка,
Мавзолей бар, димәк, Ленин бар.
Гомер юллары бит башта Казан,
Уфа, Себер аша ятканнар.
Үткәннәр дә, бүгенге дә монда
Янәш тора. Тора! Хакыйкать!
Кайнап торсын өчен тора алар
Бөек дуслык дигән хәрәкәт.
Ваня, син дә барысына: «Миндә
Татар каны бар»,— дип карама.
Безнең заман — канга кан кушылып,
Дуслык чәчкә аткан замана.
Син торасың басып, синең янда
Мин дә торам — әмма сабырмын.
Миңа шагыйрь диләр, кызны, Иван,
Син тапмасаң, ул мин табармын,
Икебез дә сабыр булыйк әле,
Син яши күр төрле үгетсез:
Ул кыз тере, Ваня, ул кан тере! —
Безнең яшәү түгел өметсез.

1986

Эчтәлеге

Милли җаным 5
Татар теле 7
«Мин үземә һәйкәл куя алмадым» 9
Бар! 10
Таяк 12
Алар өчәү иде 13
Хәтер көне 14
Шагыйрьләр һәм хатыннар 15
Булгандыр бит 17
Беренчесе 18
Кичер мине 20
Ак җилкән 21
Чит тел аша 23
Анна Ахматовага 25
Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям 27
Татар акылы 29
Мөстәкыйльлек. 31
Татар авылында 34
Париж өстендә 35
Тагын татар. 37
Талант канатында. 39
Кәңгеш борылмасы 42
Татар бугазы 43
Ачыну 46
Татар хатын-кызлары. 48
Торналар 49
Татар генераллары 50
Яшьтәш. 51
Мескен бүрек 53
«Беләм, берчак һәйкәл куелачак» 54
Казанның татар зиратында 55
Динемә карап 56
«Торып-торып искә төшә» 57
Күз яше фонтаны 58

«Бер-береңнән үрнәк алышулар» 60
Хәтерләү 61
Кәккүк тавышы 62
«Татарлардан урыска әйләнгәннәр» 63
«Туган җир-су — үзе бөек» 64
Өч тел 65
Нигә шулай? 66
Мичкә 68
«Урысны кырып карасаң диләр» 70
«Көч булганда акыл...» 70
Бүгенге тәфтиләүләр 71
Гомер сөргәндә 74
Татар каны (поэма) 76

Литературно-художественное издание

Назар Наджми
ТАТАРСКАЯ КРОВЬ

Стихи и поэма
(На татарском языке)

Җаваплы мөхәррире Рәиф Әмиров
Рәссамы Марсель Кәлимулла

ЛИК Подготовка издания к печати
Литературно-Издательская Компания

Наборга бирелде 21.10.96 ел. Басарга кул куелды 08.01.97 ел. Кәгазь форматы $70 \times 90\ ^1/_{32}$. Школьная гарнитурасы. Офсет ысулы белән басылды. Тип. кәгазе № 1. Тиражы 2000 данә. Заказ № 1152. Сатуда бәясе ирекле.

Лицензия № 152, выданная Минпечати РБ 22.03.96г.
Уфимский полиграфический комбинат.
450001, г. Уфа, проспект Октября,2.

ПРОВЕРЕНО
07 СЕН 2016
Подпись

3000